СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 2-31 от « 20 » февраля 2019 г.

«Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Мамадыш муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Россия Федерациясе Федераль законның 12 маддәсе, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставының 29 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы к а р а р к а б у л и т т е:

1. «Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Мамадыш муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. "Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын һәм аңа теркәлеп килүче материалларны Татарстан республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советында караганда Мамадыш муниципаль районы Советы вәкиле итеп Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы урынбасары Ришат Роберт улы Сәмигуллинны билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов